| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Тюлячи **КАРАР**

«20» декабря 2018 № 848

Теләче муниципаль районы белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-крайны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, соиаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фән, техника һәм культурология һәм күппрофильле өстәмә белем бирү оешмаларына 2019 елга норматив чыгымнарны раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге 273 санлы "Россия Федерациясендә белем бирү турында"гы Федераль законның 99 статьясына, 2003 елның 06 октябрендәге 131 санлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 15 статьясының 1 өлеше 11 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 санлы "Татарстан Республикасында белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-крайны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фән, техника һәм культурология һәм күппрофильле өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслауның нормативларын исәплә̱ү тәртибе турында Положениене раслау турында"гы карарына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елга расларга:

1.1. белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-крайны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фән, техника һәм культурология һәм күппрофильле өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслауга теркәлгән норматив чыгымнарны Кушымта буенча;

1.2. белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-крайны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фән, техника һәм культурология һәм күппрофильле өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслауга норматив чыгымнарга төзәтмә коэффициентны 0,5 күләмендә.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) тәэмин итәргә:

- балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнарга туры китереп тәэмин итәргә.

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына норматив чыгымнар гамәлдә булган чорда балаларга өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакларын хезмәт турындагы законнар һәм башка норматив-хокукый актлар белән каралган тәртиптә индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карарга.

3. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көннән көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан килеп туган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Карарның үтәлешенә контрольне Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның "20" 12 № 848
карарына кушымта

Теләче муниципаль районы белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-крайны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, соиаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фән, техника һәм культурология һәм күппрофильле өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга
Норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлешләре | Урнашу урыны | Бер укучыга 1 елга норматив чыгымнар (сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Беренче уку елы | Икенче уку елы | Өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетика | авыл җирлеге | 5970 | 11055 | 13266 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 5868 | 10867 | 13041 |
| Техник-иҗат | авыл җирлеге | 6273 | 11617 | 13940 |
| Туристлык-крайны өйрәнү | авыл җирлеге | 6071 | 11241 | 13491 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 6071 | 11242 | 13491 |
| Хәрби-патриотик | авыл бирлеге | 6071 | 11241 | 13491 |
| Социаль-педагогика | авыл җирлеге | 5666 | 10493 | 12591 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 5666 | 10493 | 12591 |
| Табигый-фән | авыл җирлеге | 6071 | 11242 | 13491 |